# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының
Мөслим авыл җирлеге **Катмыш** торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

27.11. 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 25 нче ноябренда узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елга, Мөслим муниципаль районы Катмыш авылында 18 яшькә җиткән һәр теркәлгән кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннары, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә һәм башка локаль конфликтларда катнашучылар, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзарасалым билгеләргә, ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук хатынын, балигъ булган балаларын, ә алар булмаганда әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итү һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1. **Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-урам утлары яктыртуга хезмәт күрсәтү өчен килешүгә түләү.

2. **Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юл эшчәнлеге:**

- Катмыш авылы эчендә юлларны язгы һәм җәйге нормативларга туры китерү (килешү нигезендә хезмәткә түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 153 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 81 , бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларнын тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 71 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 10 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең Катмыш торак пунктында гражданнар җыены узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең Катмыш авылында 18 яшькә җиткән һәр теркәлгән кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннары, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә һәм башка локаль конфликтларда катнашучылар, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендә инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзарасалым билгеләргә, ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук хатынын, балигъ булган балаларын, ә алар булмаганда әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

**1.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-урам утлары яктыртуга хезмәт күрсәтү өчен килешүгә түләү.

**2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юл эшчәнлеге:**

- Катмыш авылы эчендә юлларны язгы һәм җәйге нормативларга туры китерү (килешү нигезендә хезмәткә түләү).

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мөслим авыл җирлеге Башлыгы А.Р.Хужин